**Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Яңа-Иглай авыл җирлеге Тукай поселогы торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында**

**КАРАР**

«10» апрель 2024 ел №5

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, 2024 елның 10 апрелендә узган: «Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Яңа Иглай авыл җирлегенең Тукай торак пунктында 23.11.2023 ел № 5 гражданнар җыены нәтиҗәләре һәм Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Яңа Иглай авыл җирлегенең Тукай торак пунктында гражданнар җыены 23.11.2023 ел № 6 карары турында алдан расланган карарга түбәндәге үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертүгә ризамы:

2024 елда Яңа Иглай авыл җирлеге Тукай торак пунктында яшәүче һәм теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, балачак инвалидлары, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннары, СВОда катнашучылардан, 1 гр инвалидлардан тыш, 2000 сум күләмендә алынган үзара салымны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алдан расланган эшләр исемлеген түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

- су белән тәэмин итү һәм су чыгару системаларын, су күтәрү манараларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортлауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итүче башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау;

- торак пункт территориясен төзекләндерү (Тукай бистәсе территориясен төзекләндерү һәм тоту өчен товарлар (эшләр, хезмәтләр) сатып алу".

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:
җыенда катнашучы сайлау хокукына ия булган гражданнар исемлегенә 35 кеше кертелгән, җыенда тавыш бирүдә 21 кеше катнашты.
Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:
«ӘЙЕ» позициясе өчен халык җыенында катнашучы 20 кеше тавыш бирде;
«ЮК» позициясе өчен җыенның 1 катнашучысы тавыш бирде.
На основании изложенного, сход граждан решил:
1. Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар итте:

1. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Яңа-Иглай авыл җирлеге Тукай торак пунктында гражданнар җыенын узган, гражданнар җыены нәтиҗәләрен дөрес дип танырга.

Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Яңа Иглай авыл җирлегенең Тукай торак пунктында 23.11.2023 ел № 5 гражданнар җыены нәтиҗәләре һәм Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Яңа Иглай авыл җирлегенең Тукай торак пунктында гражданнар җыены 23.11.2023 ел № 6 карары турында алдан расланган карарга түбәндәге үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертергә:

2024 елда Яңа Иглай авыл җирлеге Тукай торак пунктында яшәүче һәм теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, балачак инвалидлары, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннары, СВОда катнашучылардан, 1 гр инвалидлардан тыш, 2000 сум күләмендә алынган үзара салымны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алдан расланган эшләр исемлеген түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

- су белән тәэмин итү һәм су чыгару системаларын, су күтәрү манараларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортлауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итүче башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау;

- торак пункт территориясен төзекләндерү (Тукай бистәсе территориясен төзекләндерү һәм тоту өчен товарлар (эшләр, хезмәтләр) сатып алу мәсьәләсе буенча кабул ителгән карарны танырга.

2. Халык җыены нәтиҗәләрен «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә «Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталы»нда, Нурлат муниципаль районының рәсми сайтында, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Яңа Иглай авыл җирлеге мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

3. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Яңа Иглай авыл җирлеге тарафыннан кабул ителгән әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә

Халык җыенында рәислек итүче: И.Х. Хәнәфиев

Яңа Иглай авыл җирлеге башлыгы
вазыйфаларын башкаручы И.Х. Хәнәфиев